**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2014 елның 14 мае № К-59/03-03

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серен кулланууга кертү тәртибе турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган күрсәтмә нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2014 елның 4 февралендәге № К-12/03-03 боерыгы белән расланган исемлегенә (алга таба – Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемлеккә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә "6. Закон проекты бүлеге башлыгы";

Исемлекнең 6,7 пунктларын тиешенчә 7,8 пунктлары дип санарга.

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Слепнева Э.И.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Министр Л.Ю. Глухова